СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

23.09.2020 № 1/6

На № ________ от ____________

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс турында**

3 чакырылыш Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советы вәкаләтләре тәмамлануга бәйле рәвештә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясына, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы уставының 48 статьясына таянып, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурсны 1 нче кушымта нигезендә игълан итәргә.
2. Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасын биләүгә дәгъва итүчеләрдән конкурска документларны 2020 елның 28 сентябреннән 2020 елның 17 октябренә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул итәргә: Яр Чаллы шәһәре, Муса Җәлил проспекты, 46 йорт, 103 каб., 08.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, көн сан, ял һәм бәйрәм көннәреннән тыш, телефон 70-66-92.
3. Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе белән контракт формасын 2 нче кушымта нигезендә расларга.
4. Татарстан Республикасы Президентының 2018 елның 6 февралендәге «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетлары җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә кандидатураларны карау өчен конкурс комиссияләре әгъзалары исемлегенә үзгәреш кертү турында» УП-134 номерлы Указын исәпкә алып, алты кешедән торган комиссия әгъзаларының гомуми санын 3 нче кушымта нигезендә билгеләргә.

5. Конкурс комиссиясенә нигезләмәдә күрсәтелгән срокларда Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасына кандидатларны конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрергә һәм конкурс нәтиҗәләре, кандидатлар турында мәгълүматны Тукай муниципаль районы Советына тапшырырга.

6. Район Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү турында хәбәрне «Якты Юл» («Светлый путь») газетасында бастырып чыгарырга, Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе белән контракт проектын Тукай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://tukay.tatarstan.ru/.

7. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны район Башлыгы урынбасарына йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе Ф.М. Камаев

Татарстан Республикасы «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының 2020 елның «23» сентябрендәге 116 номерлы карарына 1 нче кушымта

# «ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ ВАЗЫЙФАСЫН БИЛӘҮГӘ КОНКУРС ҮТКӘРҮ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

1. Әлеге нигезләмә белән «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 24 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы нигезендә «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе һәм шартлары (алга таба - Башкарма комитет Җитәкчесе) билгеләнә.
2. Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурсның (алга таба - конкурс) төп максаты булып «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру, һөнәри, эшлекле һәм әхлакый сыйфатлары буенча кадрлар сайлау һәм урнаштыру сыйфатын камилләштерү, аларның инициативалылыгын стимуллаштыру, идарә итү һәм методик эшне камилләштерү тора.
3. Конкурста катнашу хокукына 18 яшькә җиткән, Россия Федерациясе дәүләт телен белгән, эшчәнлек юнәлешенә туры килә торган югары һөнәри белемле һәм муниципаль хезмәтнең төп яки әйдәп баручы вазыйфаларында ике елдан да ким булмаган муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек буенча биш елдан да ким булмаган эш стажы булган, шулай ук «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 13 статьясында муниципаль хезмәт белән бәйле чикләүләр сыйфатында күрсәтелгән шартлар булмаган гражданнар ия.
4. Башкарма комитет Җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү һәм конкурста катнашу өчен документлар кабул итү турында хәбәр массакүләм мәгълүмат чараларында, конкурс уздырылган көнгә кадәр 20 көннән дә соңга калмыйча бастырыла.
5. Конкурс үткәрү турында хәбәрдә күрсәтелә:
1) вазыйфаның тулы исеме - Башкарма комитет Җитәкчесе;
2) әлеге вазыйфаны биләү өчен дәгъвачыга карата куелган таләпләрне үз эченә алган конкурсны үткәрү шартлары;
3) конкурсны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;
4) документларны кабул итү урыны һәм вакыты;
5) Башкарма комитет Җитәкчесе белән төзелә торган контракт проекты;
6) конкурс турында тулырак мәгълүмат чыганагы турында белешмәләр (телефон, факс, электрон почта, электрон адрес).
6. Конкурс ике этапта үткәрелә. Беренче этап конкурста катнашу өчен документлар кабул итү турында хәбәр бастыруны үз эченә ала, һәм тәкъдим ителгән документлар нигезендә конкурс комиссиясе кандидатларны конкурста катнашуга кертү турында карар кабул итә.
Конкурста катнашырга теләгән затлар түбәндәге документларны тапшыралар:
1) үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган, 4 х 6 зурлыгындагы фото, автобиография теркәлгән анкета;

2) паспорт күчермәсе яисә аны алмаштыручы документ (тиешле документ конкурска килгәч шәхсән күрсәтелә);
3) кирәкле һөнәри белем, эш стажы һәм квалификацияне раслаучы документлар:
гражданның хезмәт эшчәнлеген раслаучы хезмәт кенәгәсе яисә башка документ күчермәсе;
һөнәри белем турында, шулай ук граждан теләге буенча, өстәмә һөнәри белем хакында, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирү турында нотариаль яки хезмәт урыны буенча кадрлар хезмәтләре тарафыннан расланган документлар күчермәләре;
4) муниципаль хезмәткә кергән ел алдыннан килгән ел өчен керемнәре һәм чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;
5) гражданда муниципаль хезмәткә керүгә яки аны узуга комачаулаучы авыру булмавы турында документ.
Гариза биргән затка документлар алу турында аларның исемлеге һәм алу датасын күрсәтеп алу язуы бирелә.
Тапшырылган документларны кабул итү һәм тикшерү конкурс комиссиясе секретаре тарафыннан башкарыла.
7. Башкарма комитет Җитәкчесе вазыйфасына квалификация таләпләренә туры килмәүгә, шулай ук муниципаль хезмәткә керү һәм аны узу өчен муниципаль хезмәт турында законнарда билгеләнгән чикләүләргә бәйле рәвештә, граждан конкурста катнашуга кертелми.
Конкурста катнашуга кертмәгән очракта, граждан әлеге карарга суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы. Документларны үз вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданга конкурста катнашуга рөхсәт бирүдән баш тарту өчен нигез булып тора.
8. Конкурсның икенче этабында конкурс комиссиясе утырышларына кандидатлар буенча фикер алышу һәм конкурс нигезендә сайлап алу үткәрелә.
9. Конкурс Башкарма комитет Җитәкчесе вазыйфасына кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен бәяләүдән гыйбарәт.
Конкурс үткәрү барышында конкурс комиссиясе кандидатларны алар тапшырган белем турында документлар, граждан яисә башка дәүләт һәм муниципаль хезмәт үтү, башка хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру, муниципаль хезмәткә керүгә комачаулаучы авыру булмавы турында медицина учреждениесе бәяләмәсе, шулай ук граждан муниципаль хезмәткә кабул ителә алмый торган нигезләрнең булмавын билгеләргә мөмкинлек бирүче башка документлар нигезендә, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына каршы килми торган, кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү методларын кулланып, конкурс процедуралары нигезендә, кандидатларның үз программаларын тәкъдим итүне, шәхси әңгәмәне дә кертеп бәяли.
10. Конкурсны үткәрү нәтиҗәсендә Башкарма комитет Җитәкчесе вазыйфасына квалификация таләпләренә җавап бирүче кандидатлар ачыкланмаса, «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советы конкурс комиссиясенең конкурсны гамәлгә ашырылмаган дип тану турында беркетмәсе нигезендә кабат конкурс үткәрү турында карар кабул итә.
11. Конкурс комиссиясе утырышы, әгәр анда конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала. Конкурс комиссиясе карарлары комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавыш тигез булганда, конкурс комиссиясе рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

12. Конкурс нәтиҗәләре һәм кандидатлар турында мәгълүмат конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советы сессиясенә тапшырыла.
13. Башкарма комитет Җитәкчесен билгеләү «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советы карары белән рәсмиләштерелә. Башкарма комитет Җитәкчесен билгеләү турында карар массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыга.
14. Сайланган Башкарма комитет Җитәкчесе белән «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башлыгы контракт төзи.
15. Конкурста катнашу белән бәйле чыгымнар (конкурс үткәрү урынына бару һәм кире кайту, торак урынны наемга алу, яшәү, элемтә чаралары хезмәтеннән файдалану һ.б.) кандидатлар тарафыннан үз средстволары хисабына гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының 2020 елның «23» сентябрендәге ____ номерлы карарына 3 нче кушымта

**Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатураларны карау өчен Тукай муниципаль районы Советы тарафыннан расланган конкурс комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Закиров Рөстәм Илдус улы | Тукай муниципаль районы Башлыгы урынбасары, комиссия рәисе |
| Гончарова Ольга Анатольевна | Тукай муниципаль районы Советы депутаты, комиссия рәисе урынбасары |
| Вафин Эдуард Яфас улы | Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге идарәчесе, комиссия әгъзасы |
| Нуриев Фәнис Галиәхмәт улы | Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе баш киңәшчесе, комиссия әгъзасы |
| Хәбипов Ришат Рәшит улы | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары, комиссия әгъзасы |
| Төхбәтуллин Равил Гали улы | Тукай муниципаль районы Советы депутаты, комиссия әгъзасы. |